ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

03 03 2023 г. № 168

**Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә алкоголь продукциясе әйләнешен дәүләти җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларын гамәлгә ашыру чаралары турында**

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләти җайга салу һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү турында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясы, «Җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольле продукцияне ваклап сату һәм, җәмәгать туклануы хезмәте күрсәткәндә, алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган тирә-юнь территорияләре чикләрен билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 декабрендәге 2220 номерлы карары белән расланган җирле үзидарә органнары тарафыннан алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителмәгән кайбер оешмалар һәм объектлар тирәсендәге чикләрне билгеләү кагыйдәләренең 7 пункты нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Балалар, мәгариф, медицина оешмалары, мәдәният, спорт объектлары, күпләп һәм ваклап сату базарлары, вокзаллар, аэропортлар һәм гражданнарның башка күпләп җыелу урыннары һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән югары дәрәҗәдә куркыныч чыганаклары урнашу урыннары, алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләрнең хәрби билгеләнештәге объектлары (кушымта нигезендә) якын-тирәсендәге чикләрне билгеләргә.

2. Мәгариф идарәсенә, Мәктәпкәчә белем бирү идарәсенә, Яшьләр эшләре идарәсенә, Физик культура һәм спорт идарәсенә, Мәдәният идарәсенә, пассажирлар йөртү һәм транспорт бүлегенә, Сәламәтлек саклау идарәсенә, әлеге карар кабул ителгәннән соң 14 көн эчендә, карарның 1 пунктында күрсәтелгән эшчәнлек өлкәләрендә, урнашу урыны адресын күрсәтеп, Түбән Кама муниципаль районы территориясендә урнашкан объектлар исемлеген сәүдә һәм куллану хезмәтләре бүлегенә тапшырырга.

3. Төзелеш һәм архитектура идарәсенә, әлеге карар кабул ителгәннән соң бер ай эчендә, алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителмәгән һәр оешма һәм (яки) объект өчен тирә-юнь территорияләре чикләре схемасын, кушымтада күрсәтелгән объектлардан

алып сәүдә яки җәмәгать туклануы объектларына кадәр юлның график сурәте белән, ераклыкны метрда күрсәтеп, сәүдә һәм кулланучылар хезмәте күрсәтү бүлегенә әзерләргә һәм тапшырырга.

4. Сәүдә һәм кулланучылар хезмәтләре күрсәтү бүлегенә:

4.1. алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителмәгән тирә-юнь территорияләр чикләрен билгеләү турында муниципаль хокукый актлар проектларын әзерләргә;

4.2. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы территориясендә алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителмәгән тирә-юнь территорияләрнең чикләрен билгеләү буенча билгеләнгән тәртип нигезендә иҗтимагый фикер алышуларны әзерләргә һәм үткәрергә.

5. Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә кабул ителгән муниципаль хокукый актлар турында мәгълүматны, шулай ук әлеге актларга кушымта итеп бирелгән һәр оешма һәм (яки) объект өчен тирә-юнь территорияләре чикләре схемаларын басма массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм аны Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. «Алкогольле продукция әйләнешен дәүләти җайга салу өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актларын гамәлгә ашыру чаралары турында» Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 25 июнендәге 938 номерлы карарының үз көчен югалтуын танырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасары И.И. Мөхәмmәтҗановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районы
Башкарма комитетының
2023 елның «03» августа
168 номерлы карарына
кушымта

Балалар, мәгариф, медицина оешмалары, мәдәният, спорт объектлары, күпләп һәм ваклап сату базарлары, вокзаллар, аэропортлар һәм гражданнарның башка күпләп җыелу урыннары һәм Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләнгән югары дәрәҗәдә куркыныч чыганаклары урнашу урыннары, алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган территорияләрнең хәрби билгеләнештәге объектлары якын-тирәсендәге чикләрне билгеләргә

| т/с | Объект исеме | Сәүдә/ җәмәгать туклануы оешмасы | Якын-тирә территория чикләре * |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1 | Балалар оешмалары | Сәүдә предприятиеләре | Социаль объектның иң якын кырыйдагы ноктасыннан яки аерымланган территориянең иң якын кырыйдагы ноктасыннан (булганда) туры сызык буенча ким дигәндә 50 метр зонасында |
| | | Җәмәгать туклануы предприятиеләре | Социаль объектның иң якын кырыйдагы ноктасыннан яки аерымланган территориянең иң якын кырыйдагы ноктасыннан (булганда) туры сызык буенча ким дигәндә 50 метр зонасында |
| 2 | Мәгариф оешмалары | Сәүдә предприятиеләре | Социаль объектның иң якын кырыйдагы ноктасыннан яки аерымланган территориянең иң якын кырыйдагы ноктасыннан (булганда) туры сызык буенча ким дигәндә 50 метр зонасында |
| | | Җәмәгать туклануы предприятиеләре | Социаль объектның иң якын кырыйдагы ноктасыннан яки аерымланган территориянең иң якын кырыйдагы ноктасыннан (булганда) туры сызык буенча ким дигәндә 50 метр зонасында |
| 3 | Медицина оешмалары | Сәүдә предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 30 метр зонасында |
| | | Җәмәгать туклануы предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 25 метр зонасында |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | Мәдәният объектлары | Сәүдә предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 30 метр зонасында |
| | | Җәмәгать туклануы предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыныннан (булганда) ким дигәндә 25 метр зонасында |
| 5 | Спорт объектлары | Сәүдә предприятиеләре | Социаль объектның иң якын кырыйдагы ноктасыннан яки аерымланган территориянең иң якын кырыйдагы ноктасыннан (булганда) туры сызык буенча ким дигәндә 50 метр зонасында |
| | | Җәмәгать туклануы предприятиеләре | Социаль объектның иң якын кырыйдагы ноктасыннан яки аерымланган территориянең иң якын кырыйдагы ноктасыннан (булганда) туры сызык буенча ким дигәндә 50 метр зонасында |
| 6 | Күпләп һәм ваклап сату базарлары | Сәүдә предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 30 метр зонасында |
| | | Җәмәгать туклануы предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 25 метр зонасында |
| 7 | Вокзаллар | Сәүдә предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 30 метр зонасында |
| | | Җәмәгать туклануы предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 25 метр зонасында |
| 8 | Аэропортлар һәм гражданнарның башка күпләп җыелу урыннары һәм югары дәрәҗәдә куркыныч чыганакларының урнашу урыннары | Сәүдә предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 30 метр зонасында |
| | | Җәмәгать туклануы предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыныннан (булганда) ким дигәндә 25 метр зонасында |
| | Хәрби билгеләнештәге объектлар | Сәүдә предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 30 метр зонасында |
| | | Җәмәгать туклануы предприятиеләре | Объектка керү урыныннан яки аерымланган территориягә керү урыннан (булганда) ким дигәндә 25 метр зонасында |

Сәүдә яки җәмәгать туклануы оешмасы сәүдә комплексы эчендә булган очракта, ераклык сәүдә комплексына керү урыныннан объектның керү ишекләренә кадәр билгеләнә (аерымланган территория булган очракта – аерымланган территориягә иң якын керү урынына кадәр).

Әгәр сәүдә яки җәмәгать туклануы оешмасы объект белән бер бинада урнашкан булса, ераклык сәүдә яки җәмәгать туклануы оешмасына иң якын керү урыныннан объектка керү урынына кадәр иң кыска юл буенча үлчәнә.

Балалар, мәгариф учреждениеләреннән һәм спорт объектларыннан ваклап сату һәм җәмәгать туклануы предприятиесенә керү урынына кадәр ераклыкны исәпләүне социаль объектның иң якын кырыйдагы ноктасыннан (аерымланган территория булган очракта - аерымланган территориядән) туры сызык буенча сәүдә объектына керү урынына кадәр башкару тәкъдим ителә.

Социаль билгеләнештәге объектлар һәм кешеләр күпләп җыела торган урыннар янындагы территорияләр чикләрен исәпләү сәүдә объектына керү урыныннан медицина оешмаларына, мәдәният объектларына, күпләп һәм ваклап сату базарларына, вокзалларга, аэропортларга, гражданнарның башка күпләп җыела торган урыннарына, югары дәрәҗәдә куркыныч чыганакларының урнашу урыннарына һәм хәрби билгеләнештәге объектларга (булганда аерымланган территориягә) керү ишекләренә кадәр төзекләндерелгән җәяүлеләр юллары (тротуарлар) буенча җәяүлеләрнең бару юллары буенча башкарыла.